Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы Карары

«30» октябрь 2020 ел № 7

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендә кабул ителгән 106 номерлы «Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендә кабул ителгән 106 номерлы «җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Билгеләү:

4.1. Календарь елы салым чоры дип танылa.

4.2. Салым түләүчеләр-оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб – адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы М.С.Сабирҗанов